МИНИСТЕРСТВО
ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И
СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ
РЕСПУБЛИКИ
ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ
БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ
СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ
МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

21.02.2019 г.Казань № 130

Боерык Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2019 елның 18 мартында 5480 номеры белән теркәлде

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2012 елның 16 июлендәге 565 номерлы боерыгы белән расланган Техноген һәлакәтләр нәтиҗәсенә радиация тәэсиренә дучар булган гражданнарга азык-төлек товарларын сатып алу өчен ай саен түләнә торган акчалата компенсация билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында

Техноген һәлакәтләр аркасында радиация тәэсиренә дучар булган гражданнарга азык-төлек товарлары сатып алуга ай саен түләнә торган акчалата компенсация билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү эшен камилләштерү максатларында, боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Техноген һәлакәтләр нәтиҗәсендә радиация тәэсиренә дучар булган гражданнарга азык-төлек товарлары сатып алу өчен ай саен түләнә торган акчалата компенсация билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2012 елның 16 июлендәге 565 номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2015 ел, 5 октябрь, № 703; 2016 ел, 7 июнь, № 317; 2017 ел, 8 июнь, № 350; 2017 ел, 27 ноябрь, № 832, 2018 ел, 19 февраль, № 138; 2018 ел, 15 май, № 368, 2018 ел, 18 сентябрь, № 883 боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Техноген һәлакәтләр нәтиҗәсендә радиация тәэсиренә дучар булган гражданнарга азык-төлек товарлары сатып алу өчен ай саен түләнә торган акчалата компенсация билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган, кушымтада бирелгән үзгәрешләрне расларга.

2. Әлеге боерык рәсми рәвештә басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Министр Э.Ә. Зарипова

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 21.02.2019 № 130 боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Техноген һәлакәтләр нәтиҗәсендә радиация тәэсиренә дучар булган гражданнарга азык-төлек товарлары сатып алу өчен ай саен түләнә торган акчалата компенсация билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2012 елның 16 июлендәге 565 номерлы боерыгы белән расланган Техноген һәлакәтләр нәтиҗәсендә радиация тәэсиренә дучар булган гражданнарга азык-төлек товарлары сатып алу өчен ай саен түләнә торган акчалата компенсация билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган үзгәрешләр

1 бүлекнең 1.2 пунктында 14 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«14) һәлак булган (үлгән), нурланыш авыруын яки Чернобыль һәлакәте нәтиҗәсендә яки Чернобыль АЭС һәлакәт нәтиҗәләрен бетерү буенча эшләр башкару нәтиҗәсендә радиация тәэсиренә бәйле башка авыруларны алган яки кичергән гражданинның һәм «Чернобыль АЭС һәлакәт нәтиҗәсендә радиация тәэсиренә дучар булган гражданнарны социаль яклау турында» 1991 елның 15 маендагы 1244-1 номерлы Россия Федерациясе Законының (алга таба – 1244-1 номерлы РФ Законы) 14 статьясының беренче өлешендәге 13 пунктына ярашлы рәвештә азык-төлек товарларын сатып алу өчен ай саен түләнә торган акчалата компенсациягә хокуклы Чернобыль һәлакәте нәтиҗәсендә инвалид булган кешенең 14 яшенә җитмәгән балалары;»;

2 бүлекнең «Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасында:

2.5 пунктның 2 пунктчасындагы өченче абзацны көчен югалткан дип танырга;

3 бүлектә 3.6 пунктның өченче абзацында «телефон буенча» сүзләрен төшереп калдырырга;

Регламентка 1 нче кушымтада:

«мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме тулысынча» сүзләрен «мөрәҗәгать итүченең Ф.И.А. (соңгысы – булган очракта)» сүзләренә алмаштырырга;

«Ф.И.А.» сүзләрен «Ф.И.А. (соңгысы – булган очракта)» сүзләренә алмаштырырга;

4 пунктны төшереп калдырырга.